ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.64, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

26.11.2025 с. Татарское Бурнашево 19

Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Борнаш авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2025 елның 21 ноябрендәге 1,2 номерлы; 2025 елның 22 ноябрендәге 3 номерлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә гражданнарга үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин

Борнаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 26 ноябрендәге
19 номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 2026 елның 1нче гыйнварыннан 2026 елның 31нче мартына кадәр гражданнар җыенында катнашуга һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
В) СВО катнашучылары

4. Аерым категория гражданнар өчен:
а) 1 төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешма аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) https://uslugi.tatarstan.ru/почта күчерүләрен гамәлгә ашыруга хокуклы оешмалар аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактынраслый.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 26 ноябрендәге
19 номерлы карарына
2 нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) №№ _____________

Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер мәртәбә түләнә торган түләү турында
Түләүче Ф.И.А.и. ________________________________________
Адрес: ________________________________________________________
Нигезендә ____________________________________________
Сезгә чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр бирелә торган түләүне ___________ сум күләмендә________кадәр срокта түләргә кирәк,
түбәндәге реквизитлар буенча: ______________________________________
БИК алучы Банк _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучы. Сч № ________________________________________
ИНН _________________________________________
КПП _________________________________________
КБК _______________ _ ОКАТО__________________
Түләү билгеләмәсе __________________________________________
Җитәкчесе _________________ ________________________________
М. У. (имза) (имзаны киңәйтү)
- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -
Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләнә торган түләү турында
________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф.И.А.и. __________________________________
Адрес: ___________________________________
Алдым «__» ________________ 20________ел _________________________
Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек төпсәсе тутырыла һәм Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.